Республика Татарстан

СОВЕТ САБИНСКОГО
ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА

422060, Республика Татарстан, Сабинский район,
п.г.т. Богатые Сабы, ул. Школьная, 31а
тел. 2-30-32, 2-31-35
Факс 8(84362) 2-32-35

e-mail: sab.sab@tatar.ru

Татарстан Республикасы

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
САБА ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

422060, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Байлар Сабасы ш.т.б., Мәктәп урамы, 31а йорт
тел. 2-30-32, 2-31-35
Факс 8(84362) 2-32-35

РЕШЕНИЕ — КАРАР

«03» апрель 2019 ел — № 13

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге Советының 2014 нче елның 19 нчы ноябрендә кабул ителгән 44 нче номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге территориясендә физик затларның милкенә салым турында"гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, Россия Федерациясе Бюджет Кодексының 64 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге Советының 2014 нче елның 19 нчы ноябрендә кабул ителгән 44 нче номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге территориясендә физик затларның милкенә салым турында»гы карарына (Советның 2015 нче елның 10нчы августында кабул ителгән 39нчы, 2015 нче елның 7 нче октябрендәге 9нчы, 2018 нче елның 3 нче августындә кабул ителгән 22нче карарлары, 2018 нче елның 29нчы ноябрендә кабул ителгән 43 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 пунктны түбәндәгечә бәян итәргә:

" 3. Түбәндәге ташламаларне кертергә:

3.1. Ике фатирдан торган күпфатирлы бер катлы торак йорттагы фатирга милек хокукы булган физик затларга әлеге фатирның гомуми мәйданының кадастр бәясендәге салым ставкасының процент өлеше буларак билгеләнә торган суммага исәпләнгән салым суммасын киметү рәвешендә бирелә.

Әгәр фатир гомуми өлешле милектә булса, ташламалар суммасы өлешләп милектәге һәр кеше өчен аның бу фатирга милек хокукындагы өлешенә пропорциональ рәвештә исәпләнә.

Шул ук вакытта әлеге пункт нигезендә исәпләнгән ташламалар суммасы исәпләнгән салым суммасыннан артып китә алмый.

3.2. 18 яшькә кадәрге өч һәм аннан күбрәк балалары булган гражданнар-физик затлар милкенә салым түләүдән азат ителә.

Салым ташламасы салым салу объектларының чикләнмәгән санына карата бирелә.

Салым ташламасы салым салу объектларының теләсә нинди төренә карата бирелә.

Салым ташламаларына хокукы булган физик затлар салым органына салым ташламалары бирү турында гариза бирәләр, шулай ук салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслаучы документлар бирергә хокуклы.».

2. Әлеге карарның йогынтысын 2018 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә җәелдерергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы, шәһәр җирлегендә урнашкан информацион стендларда һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/rus/saba адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Саба шәһәр
җирлеге башлыгы урынбасары Р.М.Хәсәнов